Т Р Сарман муниципаль районы
мәктәпкәчә белем бирү
муниципаль бюджет учреждениясе
Җәлил бистәсе гомуми үсеш төрендәге
1 № “Каенкай” балалар бакчасы
I категорияле татар теле тәрбиячесе
Афзалова Алия Мөнәвир кызы.





Абдулла Алиш 1908 елның 15 сентябрендә Татарстанның Куйбышев районы Көек авылында дөньяга килә. Аның бабасы Нурулла авылмулласы булган, әтисе Габделбари абзый иген иккән, умарта караган. Ул өйгә төрле газета-журналлар алдырган, балаларны кече яшьтән үк хезмәткә өйрәтергә, белемле һәм тәрбияле итәргә тырышкан. Абдулланың әнисе Газизә апа да авыл халкы арасында укымышлы хатын саналган, әдәбиятны бик яратып, шигырь һәм бәетләр чыгарырга һәвәс булган.



Абдулла шушы тату, хөр фикерле һәм хезмәт сөючән гаиләдә кечкенәдән ук зирәк һәм зиһенле малай булып үсә, алты-җиде яшьләрендә әтисеннән укырга-язарга өйрәнә, аннары авылдагы башлангыч мәктәптә укый башлый. Абдулла Ямбакты авылы мәдрәсәсендә , Бураково авылын мәктәбендә укый, аннары җидееллык рус мәктәбен тәмамлый . Мәктәптә уку елларында А. Алиш драма һәм әдәбият түгәрәкләре, концертлар оештыру, стена газеталары, кулъязма журналлар чыгару кебек эшләрдә башлап йөруче була, үзе дә шигырьләр, хикәяләр яза.



А. Алиш Казан Җир төзү техникумында укый башлый. әдәбият белән кызыксынуы тагын да үсә: ул әдәбият түгәрәкләренә йөри . Әдипнең «Капкорсак патша» исемле беренче әкияте «Пионер каләме» журналында басылып чыга . Шуннан соңгы елларда (1935— 1940) А. Алиш ике дистәдән артык әкият иҗат итә..

Бөек Ватан сугышы башлангач, А.Алиш 1941 елның июль аенда фронтка китә, солдат-радист сыйфатында, Орлов өлкәсендә барган каты сугышларда катнаша. 1941 елның 12 октябрендә Брянск шәһәре янында, Десна елгасы буенда чолганышта калып, фашистлар кулына әсир төшә.

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, алар белән бергә антифашистик оешмада эшли башлый. 1943 елның августында, яшерен оешманың эше ачылып, А. Алиш һәм башка җәлилчеләр кулга алыналар һәм фашист суды тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителәләр. 1944 елның 25 августында 12 сәгать 12 минутта фашист палачлары Абдулла Алишны гильотинада җәзалап үтерәләр.








# Уен – табышмак
# «Бу кайсы әкияттән?»

Соскы борын –
бакылдык,

Күп сөйләшә –
такылдык.



Җәй буе бал җыя,
Кыш буе хәл җыя.



- Алгы тәпиләре кыска,
- Чабарга ул бик оста.
- Соры тунын сала да,
- Ак тунын кия кышка.



- Башы -  тарак, койрыгы -  урак.
- Кычкыртып быргысын, уята барысын.



# Үстерешле уен
# “Бу кайсы әкият ?”








ТУКМАР







